| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.11.2016 Казан ш. № 6-176/тп

2017 елга газдан файдалану җайланмаларын «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләренә технологик тоташтырган өчен түләү билгеләү турында

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ санлы Федераль законга, «Россия Федерациясе территориясендә газ өчен түләү бәясен, аны транспортировкалау хезмәтләрен күрсәтү өчен тарифларны, газдан файдалану җайланмаларын газ бүлү челтәрләренә техник тоташтыру өчен түләүләрне дәүләти җайга салу турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 елның 29 декабрендәге 1021 санлы карарына, «Газдан файдалану җайланмаларын газ бүлү челтәрләренә техник тоташтыру өчен түләү күләмен һәм (яки) аның күләмен билгеләүче стандартлаштырылган тариф ставкаларын исәпләп чыгару буенча Методик күрсәтмәләрне раслау турында» тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2014 елның 28 апрелендәге 101-э/3 санлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Газдан файдалану җайланмаларын «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләренә технологик тоташтырган өчен түләүне әлеге карар кушымтасына нигезләнеп билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнелгән түләү 2017 елның 1 гыйнварыннан 2017 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Газдан файдалану җайланмаларын «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләренә технологик

тоташтырган өчен икътисадый яктан нигезләнгән түләү 153,23 мең сум тәшкил итә.

4. Әлеге карар кушымтасында күрсәтелгән гариза бирүчеләр категорияләрен тоташтырудан «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең төшеп калучы керемнәрен 1 829,936 мең сум күләмендә билгеләргә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң ун көннән узгач, үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча дәүләт комитетының
11.11.2016 № 6-176/тп
карарына кушымта

# 2017 елга газдан файдалану җайланмаларын «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләренә технологик тоташтырган өчен түләү

| № п/п | Гариза бирүчеләр категорияләре | Ераклыгы гариза бирүченең җир кишәрлеге чикләреннән газ бүлү челтәрләренә кадәр | Технологик тоташтырган өчен түләү, сумда | |
|---|---|---|---|---|
| | | | НДСтан тыш | НДСны исәпкә алып <*> |
| 1. | Газның сәгатенә 5 куб метрдан артмаган максималь чыгымнары белән, гариза бирүчеләрнең газдан файдалану җайланмалары алданрак әлеге ноктада тоташтырылган газ чыгымнарын исәпкә алып (газны эшмәкәрлек(коммерцияле) максат-ларда кулланырга исәп тотмаган башка гариза бирүчеләр өчен), газдан файдалану җайланмасыннан алып гариза бирелгән газ бүлү оешмасының газ бүлү челтәренә кадәр аралыгы проект куәте 0,3 МПадан артык булмаган басым белән турыдан озынлыгы 200 метрдан артмаган шартларда һәм әлеге чаралар бары тик газ кертү-газүткәргечләр (газ көйләү пунктлары корылышыннан тыш) төзүне күздә тоталар. | 10 метрга кадәр (шул исәптән) | 20 335,90 | 23 996,36 |
| | | 10 метрдан алып 20 мга кадәр ( шул исәптән) | 30 503,85 | 35 994,54 |
| | | 20 метрдан артыграк | 50 839,75 | 59 990,90 |
| 2. | Газның сәгатенә 15 куб метрдан артмаган максималь чыгымнары белән, гариза бирүчеләрнең газдан файдалану җайланмалары алданрак әлеге ноктада тоташтырылган газ чыгымнарын исәпкә алып (газны эшмәкәрлек(коммерцияле) максат-ларда кулланырга исәп токан гариза бирүчеләр өчен), газдан файдалану | 200 метрга кадәр ( шул исәптән) | 50 839,75 | 59 990,90 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | җайланмасыннан алып гариза бирелгән газ бүлү оешмасының газ бүлү челтәренә кадәр аралыгы проект куәте 0,3 МПадан артык булмаган басым белән турыдан озынлыгы 200 метрдан артмаган шартларда һәм әлеге чаралар бары тик газ кертү-газүткәргечләр (газны көйләү пунктлары корылышыннан тыш) төзүне күздә тоталар. | | | |

<*> Физик затлар гариза бирүчеләр булып торган очракларда

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештыру һәм җайга салу бүлеге